Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Көчек авыл җирлегенең Түбән Көчек торак пунктында
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**2019 ел, 28 ноябрь** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Түбән Көчек торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ:**

1. Көчек авыл җирлеге Түбән Көчек авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан тыш, 2020 елда 400 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:
- Түбән Көчек авылында Калинин һәм Казан урамнарына вак таш түшәү;
- Түбән Көчек авылының Яңа һәм Ленин урамнарында су челтәрен алыштыру;
- Түбән Көчек авылы суэтем башнясына тирәнгә насос сатып алу;
- Түбән Көчек авылы суэтем башнясын санитар саклау йөзеннән койма белән әйләндереп алу;
- Түбән Көчек авылы зират коймасын тоту;
-Түбән Көчек авылы янгын сүндерү машинасының штаттан тыш хезмәткәренә хезмәт хакы түләү;
- Түбән Көчек авылында Бөек Ватан сугышы һәйкәлен төзекләндерү;
- Кеше тормышына һәм сәламәтлегенә яный торган корыган агачларны кисү.
- Түбән Көчек авылы юлларын кыш көне кардан чистарту.
3. Гражданнарның җыен нәтиҗәләрен Көчек авыл җирлеге мәгълүмати стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек Башлыгы Р.Ә. НУРМӨХӘМӘТОВ